**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 996

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 сентябрь, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1939 нчы ; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.20, 4.1.62, 4.2.22 нче пунктларда «җирлекләр, шәһәр округлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.27 нче пунктта «җирлекләр яки шәһәр округлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.39 нчы пункт үз көчен югалткан дип санарга;

4.1.30 нчы пунктта «төбәк дәүләт» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.75 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.75. Татарстан Республикасында тотылган транспорт чараларын махсус куеп тору урыннарына илтүгә һәм анда саклауга тарифлар, шулай ук алар өчен түләү вакытларын билгели;»;

4.1.102 нче пунктка «... карап тикшерүгә» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына һәм (яки)» сүзләрен өстәргә;

4.2.11 нче пунктта «тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендә вәкаләтләр бирелгән орган,» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6.8 нче пункт өстәргә:

«6.8. Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\996.doc